**Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе**

# БОЕРЫК

« 19 » август 2014 ел № 112 -тэ

Казан

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү турындагы Кагыйдәнамәне раслау турында

2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ "Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында"гы Федераль канун белән, 2005 елның 1 февраленнән № 112 "Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен бәйге турында"гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы белән,2003 елның 16 гыйнварыннан № 3-ЗРТ "Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында"гы Татарстан Республикасы Кануны белән тәңгәл килеп

**б о е р а м :**

1. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү турындагы Кагыйдәнамәне расларга.
2. Гамәлдәге боерыкның үтәлүен тикшерүне үз артымнан калдырам.

Идарә башлыгы Д.А.Иванов

2014 елның “19”август № 112-тэ
Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе боерыгы белән расланган

**Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү турында Кагыйдәләр.**

## I. Гомуми кагыйдәләр

1. Гамәлдәге Кагыйдәнамә белән Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү комиссиясенең катнашмасы, эш вакыты һәм тәртибе (соңыннан - бәйге комиссиясе), ә шулай ук Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә (соңыннан – Идарә) Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйгене үткәрү методикасы билгеләнә.

2. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйгенең төп бурычлары:

Россия Федерациясе гражданнарының, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенә бертигез дәрәҗәдә хокук бирү конституция белән тәэмин ителә; ( соңыннан – гражданлык хезмәте);

Идарәдәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен ( соңыннан – гражданлык хезмәткәрләре) бәйге нигезендә хезмәттәге үсеш хокукы белән тәэмин итү;

Идарәдә, дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру, кадрлар резервын формалаштыру;

бәйге нигезендә югары һөнәрле кадрлар катнашмасын сайлап алу һәм формалаштыру;

кадрларны табу һәм билгеләү буенча эшне камилләштерү.

3. Бәйге, Идарәдә, “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Федераль канун һәм Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Татарстан Республикасы Кануны белән тәңгәл килеп, гражданлык хезмәтенең буш урыны булган очракта, Идарә башлыгы карары буенча игълан ителә.

Бәйгене уздыру турында карар, Идарә башлыгы белән, Идарәнең кадрлар хезмәте әзерләгән, мотивлаштырылган язма гариза нигезендә кабул ителә.

Гариза, бәйге уздыру турында тәкъдим белән беррәттән, гражданлык хезмәте вазифасының исемен һәм , хезмәттәге бурычларының үзенчәлекләрен күздә тотарга,

эзләүчегә куела торган таләпләрне үз эченә алырга тиеш. ( гамәлдәге Кагыйдәнамәгә 3нче кушымта)

4. Идарәдә бәйге үткәрелми:

Идарәдә гражданлык хезмәтенең “башлыклар” һәм “булышчылар(киңәшчеләр)” категориясенә билгеле бер вакытка эшкә билгеләнгән очракта;

срогы булган хезмәт контракты төзү очрагында;

гражданлык хезмәткәрен, 2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Федераль канунның 28 маддәсенең 2 бүлегендә, 31 маддәнең 1 бүлегендә һәм 60.1. маддәнең 9 бүлегендә каралган, башка гражданлык хезмәтенә күчергән очракларда;

Гражданнар хезмәте резервына кертелгән гражданинны гражданлык хезмәтенә билгеләнгән очракларда;

5. Бәйге үткәрелмәскә мөмкин:

Идарә боерыгы белән раслана торган вазифалар исемлеге буенча, хезмәтне үтәү, дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән бәйле булган, гражданлык хезмәтенең аерым вазифаларына билгеләгән очракта;

Идарә башлыгының карары буенча, гражданлык хезмәтенең кече вазифаларына билгеләгән очракта;

6. Бәйге, гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы кандидатларның һөнәри дәрәжәсен билгеләүдән, аларның бу вазифага куелган квалификацион таләпләргә туры килүен бәяләүдән тора.

## II. Бәйге комиссиясенең формалашу һәм эш тәртибе.

7. Идарәдә бәйге үткәрү өчен Идарә башлыгы боерыгы белән бәйге комиссиясе оештырыла.

8. Бәйге комиссиясе рәистән, рәиснең урынбасарыннан, сәркатиптән, комиссия әгъзаларыннан тора.

Гражданлык хезмәтенең “башлыклар” категориясендә буш урынны алмаштыруга бәйге уздыру өчен, бәйге комиссиясе белән Идарә башлыгы үзе җитәкчелек итә.

Гражданлык хезмәтенең башка буш урыннарын алмаштыруга бәйгеләр уздыру өчен, Идарә башлыгының боерыгы белән, гражданлык хезмәтенең төрле дәрәҗәсе һәм төркеме өчен, берничә бәйге комиссиясе оештырылырга мөмкин.

9. Комиссия рәисе бәйге комиссиясе эшчәнлеге белән идарә итә, утырышны үткәрү вакытын һәм аның көн тәртибен билгели, комиссия утырышларында рәислек итә һәм документларга имза куя. Комиссия рәисе булмаган очракта, аның хокукларын һәм бурычларын бәйге комиссиясе рәисенең урынбасары үти.

Бәйге комиссиясенең рәисе белән бәйге әзерләү һәм уздыру буенча эш группасының катнашмасы раслана.

Бәйге комиссиясенең сәркатибе комиссиянең эшен тәэмин итә (регистрацияләү, гаризаларны кабул итү, комиссиянең беркетмәләрен алып бару).

10. Бәйге комиссиясенең катнашмасына Идарә башлыгы, башлыкның урынбасары, Идарәдә кадрлардагы эшне башкару өчен җаваплы зат, Идарәдә

Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрүче Идарәнең структур бүлекчәсенең җитәкчесе яки аның урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты вәкиле, Идарә карамагындагы Иҗтимагый киңәшмә вәкиле, ә шулай ук Идарәнең башлыгы соравы буенча, Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты белән чакырылган, гражданлык хезмәте буенча бәйсез экспертлар булып, шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә, фәнни, уку-укыту оешмаларының һәм башка оешмаларның вәкилләре кертелә.

Вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны, бәйге комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан, дүртнең бер өлешеннән дә ким булмаска тиеш.

11. Идарәдә, гражданлык хезмәтен үтәү дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән бәйле булса, Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү комиссиясе катнашмасы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы кануннарын исәпкә алып формалаша.

12. Бәйге комиссиясенең катнашмасы, бәйге комиссиясенең кабул итә торган карарларына йогынты ясый торган, ихтыяҗлар бәрелеше булмауны искәртеп формалаштырыла.

13. Бәйге комиссиясенең утырышы Идарәдә гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыруга (кадрлар резервына кертүгә) ике кандидаттан да ким булмаган очракта уздырыла һәм аның гомуми әгъзаларыннан өчтән ике өлеше булган очракта хокуклы дип санала. Гражданлык хезмәтендәге урыннарны биләгән, комиссия әгъзалары гына катнашкан, утырышны уздыру ярамый.

14. Бәйге уздыру нәтиҗәләре буенча, бәйге комиссиясенең карары, утырышта булган бөтен әгъзаларның ачык тавыш бирүе белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

Кабул иткән карар белән килешмәсә, бәйге комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы,үзенең аерым карашын белдерә ала. Аны комиссия утырышының беркетмәсенә теркиләр һәм шул бәйге комиссиясе әгъзаның имзасы белән беркетәләр.

15. Бәйге комиссиясенең карары кандидат үзе булмаган вакытта кабул ителә һәм аны гражданлык хезмәтенең буш урынына билгеләүнең, кадрлар резервына кертүнең яки кире кагуның нигезе булып тора.

16. Бәйге комиссиясенең әгъзалары белән кабул иткән карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре), бәйге комиссиясенең беркетмәсе (гамәлдәге Кагыйдәнамәгә 5нче кушымта) белән рәсмиләштереләләр. Аңа рәис, рәиснең урынбасары, сәркатип, комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашкан бәйсез эксперт белән кул куела.

17. Бәйгене уйлау һәм әзерләү буенча эш документларының эчтәлеге, бәйге комиссиясенең утырыш беркетмәләре, бәйге утырышларының сораулары һәм темалары исемлеге бәйге беткәнчегә кадәр хезмәт кулланыуы өчен мәгълүмат булып тора.

18. Бәйгене, бәйге комиссиясенең эшен оештыру һәм уздыру бәйге комиссиясенең сәркатибе башкара.

## III. Бәйгедә катнашучылар

19. Бәйгедә катнашуга, Идарәдә гражданлык хезмәтендәге буш урынны алмаштыруга (кадрлар резервына кертү) куелган таләпләргә туры килгәнәм куелган вакыт эчендә бөтен кирәкле документларны тапшырган, гражданнар кертелә.

Идарәдә гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы кандидатларга (кадрлар резервына кертү) куелган таләпләр (гамәлдәге Кагыйдәнамәгә 1нче кушымта) һәм Идарәдә гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы (кадрлар резервына кертү) кандидатларга бирелә торган әсбаплар һәм документлар исемлеге (гамәлдәге Кагыйдәнамәгә 2нче кушымта) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турындагы кануннары нигезендә урнаштырылды

20. Бәйгедә катнашу өчен документлар, Идарәнең рәсми сайтында һәм "Интернет" челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасында, аларны кабул итә башлау турында белдерү урнаштырылган көннән алып, 21 көн эчендә Идарәгә бирелергә тиеш.

21. Документларны үз вакытында, тулы күләмдә бирмәү яки дөрес тутырмау хөрмәтлене сәбәбеннен, аларны кабул итмәскә нигез булып тора.

Документларны үз вакытында, тулы күләмдә бирмәүнең яки дөрес тутырмауның мөһим сәбәбе булса, Идарә башлыгы аларны кабул итү вакытын күчерергә хаклы.

## IV. Бәйгене үткәрү методикасы

22. Бәйгене үткәргәндә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының кануннарына каршы килмәгән, кандидатларның шәхси һәм һөнәри сыйфатларын бәяләү методларына нигезләнгән бәйге биремнәре һәм эшләре кулланыла.

23. Кандидатларның шәхси һәм һөнәри сыйфатларын бәяләүнең критерийлары, Идарәнең гражданлык хезмәтенең вазифаларына куела торган квалификацион таләпләр нигезендә эшкәртелде.

Якынча исемлек һәм бәйгедә катнашучыларны бәяләү критерийларының кыскача тасвирламасы гамәлдәге Кагыйдәнамәнең 6 нчы кушымтасында китерелгән.

Бәйге үткәрелә торган төркемгә һәм вазифаның категориясенә карап, бәйгедә катнашучыларны бәяләү критерийлары үзгәрергә мөмкин.

24. Бәйге уздырганда, бәйге комиссиясе, кандидатларның белем алуын, гражданлык яки башка дәүләт хезмәтен үтүен, башка урында эшләвен, тапшырган документларына нигезләнеп бәяли, шәхси һәм профессиональ сыйфатларын – аерым әңгәмә кулланып бәяли.

25. Бәйге ике этапта үткәрелә.

Беренче этапта Идарә документларны кабул итү турында белдерүне Идарәнең рәсми сайтларында һәм "Интернет" челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт информацион системасында урнаштыра.

Документларны кабул итү турында белдерүдә гражданлык хезмәтендәге буш вазифаның исеме ( кадрлар резервы формалаштыра торган вазифа), бу вазифаны

алмаштырырга теләүче кандидатка таләпләр, гражданлык хезмәтен үтү шартлары, гамәлдәге Кагыйдәнамәнең 2 нче кушымтасына карап бирергә кирәкле документларны кабул итү вакыты һәм урыны, күрсәтелгән документларның кайсы вакытка кадәр кабул ителүе, бәйге үткәрүнең якынча вакыты, аны үткәрүнең урыны һәм тәртибе,бүтән мәгълүмати әсбаплар күрсәтелә.

Бәйгенең беренче этабы документларны кабул итү турында белдерүне Идарәнең рәсми сайтларында һәм “Интернет” челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт информацион системасында урнаштыру көненнән алып башлана һәм 21 көннән дә иртә тәмамланмый.

26. Идарәдә гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштырырга теләүче кандидатлар (кадрлар резервына кертү) биргән документларны тикшергәннән соң, кадрлар хезмәте, документларны кабул итү тәмамлангач, 7 көн эчендә Идарә башлыгына гражданнарны бәйгегә кертү яки кертмәү очрагында, мотивлаштырылган кире кагу турында карар чыгару өчен тәкъдим кертәләр.

Претендентларның тикшерелгән документлары һәм кадрлар хезмәтенең тәкъдимнәре Идарә башлыгына, бәйгенең 2 этабын үткәрү турында карар кабул итү өчен, тапшырылалар.

27. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының кануннары белән тәңгәл килеп, тикшерү барышында урнаштырылган , гражданинның гражданлык хезмәтенә керергә киртә булырлык шартлар туса, ул кадрлар хезмәте белән бәйгедә катнашуга кире кагуның сәбәпләре турында (гамәлдәге Кагыйдәнамәнең 4 нче кушымтасы) карар кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә язма рәвештә белдерелә.

28. Бәйгедә катнашуга кертелмәгән, буш урынны биләргә теләүче претендент, Россия Федерациясе кануннары белән тәңгәл килеп, ул карарны шикаять итәргә хокуклы.

29. Бәйгенең беренче этабы бетүнең шарты, кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итеп, куелган таләпләргә туры килүче ике яки икедән артык кандидат булу.

Бәйгедә катнашуга кертелгән гражданнарга, кадрлар хезмәте, бәйгенең икенче этабы башланганчыга кадәр 15 көн алдан, бәйгене үткәрү вакыты һәм урыны турында СМС хәбәр җибәрәләр.

30. Бәйгенең икенче этабында кандидатларны бәяләү өчен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының кануннарына каршы килмәгән, кандидатларның шәхси һәм профессиональ сыйфатларын бәяләү методларына нигезләнгән бәйге биремнәре(тест) һәм эшләре кулланыла.

Кандидатларга бирелә торган тест сынаулары язма рәвештә уздырылалар. Бәйге комиссиясе тестларга сораулар исемлеге төзи, ә шулай ук дөрес булмаган җаваплар санын ( яки процентын) билгели.

Дөрес булмаган җаваплар саны 25% артык булырга тиеш түгел.

Сораулар исемлеге гомум танышу өчен ачык булырга тиеш. Тест шул исемлектә булган сораулардан төзелә. Бәйгедә катнашучыларның тхбәндәге сораулар буенча белемен тикшерерүне тәэмин итәргә тиеш:

Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе;

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турындагы кануннары;

Идарә турында Кагыйдәнамә;

гражданлык хезмәте вазифасының вазифаи регламенты;

структур бүлекчәнең эшчәнлек юнәлеше буенча хокукый-норматив актлар.

Гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштырырга теләүче кандидатларга ( кадрлар резервына кертү) Идарәдә тестны язарга бертигез вакыт бирелә.

Тестны бәяләү, бәйге комиссиясе белән, дөрес җаваплар саны буенча, кандидат үзе булмаганда уздырыла.

31. Бәйге комиссиясенең карары кандидат үзе булмаганда кабул ителә һәм аны гражданлык хезмәтенең буш урынына билгеләүгә яки билгеләмәүгә нигез булып тора.

Бәйге комиссиясе, гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыруга уздырылган, ләкин бәйгедә җиңмәгән, кандидатның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган очракта, Идарәнең кадрлар резервына кертү турында, киңәш бирү характерындагы карар кабул итә ала.

32. Бәйге комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре, рәис, рәис урынбасары, сәркатип, комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашучылар кул куйган, карар белән рәсмиләштерелә.

33. Бәйге нәтиҗәләре буенча Идарә башлыгы белән, бәйгенең җиңүчесен гражданлык хезмәтенең буш урындагы вазифага билгеләү турында боерык бастырыла һәм җиңүче белән хезмәт контракты төзиләр.

Әгәр дә бәйге комиссиясе белән, гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен уздырылган бәйгедә, Идарәнең кадрлар резервына, җиңмәгән кандидатны кертергә карар чыгарылган булса, ул очракта күрсәтелгән затның ризалыгы буенча, аны гражданлык хезмәтендәге буш урындагы вазифа караган төркемдәге, гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен Идарәнең кадрлар резервына кертү турында боерык бастырыла

34. Кандидатларга бәйгенең нәтиҗәләре турында хәбәр, язма рәвештә, бәйге беткәннән соң җиде көн эчендә җибәрелә. Бәйгбенең нәтиҗәләре турында мәгълүмат, шулай ук Идарәнең рәсми сайтында һәм “Интернет” челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

35. Гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштырырга теләгән, ләкин бәйгегә кертелмәгән, яки катнашып җиңмәгән кандидатларның документлары язма рәвештәге гариза буенча, бәйге беткәннән соң, өч көн эчендә кайтарылырга мөмкин. Ул вакыт үткәнчегә хәтле документлар Идарәнең архивында сакланалар, аннан соң юк ителәләр.

36. Бәйгедә катнашу белән бәйле чыгымнар (бәйге үткәрү җиренә бару һәм кайту өчен түләү, бүлмәдә түләп вакытлыча тору, элемтә өчен түләү һ.б.), кандидатлар белән үз акчасыннан түләнә.

37. Кандидат,бәйге комиссиясенең карарын, Россия Федерациясе кануннары белән тәңгәл килеп, шикаятьләргә мөмкин

2014 елның “19”август № 112-тэ
Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе боерыгы белән расланган Кагыйдәнамәгә
1нче кушымта.

**Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы (кадрлар резервына кертү) кандидатларга куелган таләпләр.**

I. Гомуми таләпләр

1. 18 яшьтән дә кече булмаган, Россия Федерациясенең дәүләт телендә сөйләшүче, Идарәдә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) кирәкле Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының кануннары белән билгеләнгән таләпләргә туры килгән, Россия Федерациясенең гражданнары бәйгедә катнашырга хокуклы

Гражданлык хезмәткәре, бәйге уздыру вакытында нинди вазифаны алмаштыруга карамыйча, гомуми нигезләрдә бәйгедә катнашырга хокуклы.

2. Бәйгедә катнашуга гражданин түбәндәге очракларда кертелми:

1) канунлы көчкә кергән, хөкем карары белән аны эшкә яраксыз яки чикле күләмдә эшкә яраксыз дип танысалар;

2) канунлы көчкә кергән, хөкем карары буенча гражданлык хезмәте вазифасы буенча бурычларын үтәү мөмкин булмый торган, җаза бирүгә хөкемләсәләр, ә шулай ук федераль канун белән билгеләнгән тәртиптә өстеннән алынмаган яки ахырга хәтле түләнмәгән хөкемгә тартылуы булган очракта;

3) гражданлык хезмәтенең вазифасын алмаштырырга дәгъваласа яки гражданлык хезмәткәре алмаштырган гражданлык хезмәтенең вазифасы буенча вазифаи бурычларын үтәү, федераль канун белән саклана торган дәүләти яки башка серне тәшкил иткән мәгълүматларны куллану белән бәйле булса , мәгълүматны куллану хокукы тәртибен үтүдән баш тарту;

4) медицина оешмасы карары белән расланган,гражданлык хезмәтенә керергә яки аны үтүгә кымачау итүче авыру булуы;

5) гражданлык хезмәтенең вазифасын алмаштыру бер-берсенә турыдан-туры буйсынучанлык яки контрольлелек белән бәйле булса, гражданлык хезмәткәре белән якын кардәшлек яки туганлык( әти-әни, ир-хатын, балалар, абыйлар-апалар, ә шулай ук ир-хатынның әти-әниләре, балалары, абыйлары-апалары);

6) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу яки башка ил гражданлыгын алу;

7) башка ил гражданлыгы булу (башка илләр), башкасы Россия Федерациясенең халыкара килешүнамәсе белән каралмаган булса;

8) гражданлык хезмәтенә урнашканда ялган документлар яки ялган мәгълүмат бирү;

9) 2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ "Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында"гы Федераль канун белән белән урнаштырылган мәгълүматларны бирмәү, яисә керемнәре, милке һәм милки йөкләмәләр турында ялган мәгълүмат бирү;

10) чикләүләрне һәм тыюларны, ихтыяжлар бәрелешен булдырмау яки хәл итү таләпләрен сакламаган һәм 2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ "Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында"гы Федераль канун, 2008 елның 25 декабреннән №273-ФЗ " Коррупциягә каршылык күрсәтү турында"гы Федераль канун һәм башка Федераль канунар белән коррупциягә каршы тору максаты белән урнаштырылган, вазифаларын үтәмәгән очракларда, яллаучының вәкиле белән гражданлык хезмәткәренә карата ышанычын югалту;

11) канунлы нигезе булмыйча, өндәү комиссиясе карары белән тәңгәл килеп, аны өндәмә буенча хәрби хезмәтне узмаган дип таныган чакта ( чыгарма артыннан контракт буенча хәрби хезмәтне узган гражданнар);

## II. Квалификацион таләпләр

3. Белемгә һәм гражданлык хезмәтенең стажына яки эш стажына квалификацион таләпләр.

Гражданлык хезмәтендәге вазифаларга куелган таләпләрнең санына, "җитәкчеләр", "булышчылар(киңәшчеләр) категорияләренә, гражданлык хезмәтендәге бөтен төркем "белгечләр" , ә шулай ук гражданлык хезмәтенең баш һәм алдан баручы төркемнәрен "тәэмин итүче белгечләр" категориясе югары белемле булу кирә.

Гражданлык хезмәтендәге вазифаларга куелган таләпләрнең санына, гражданлык хезмәтенең өлкән һәм кече төркемнәрен "тәэмин итүче белгечләр" категориясе урта профессиональ белемле булу кирә.

Белгечлек буенча, гражданлык хезмәткәрләре өчен әзерлек юнәлеше буенча, гражданлык хезмәтенең стажына яки эш стажына түбәндәге квалификацион таләпләр куела:

баш төркемнең бөтен категорияләрендәге гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен – алдан баручы яки өлкән төркем гражданлык хезмәте вазифаларында гражданлык хезмәте стажы ике елдан да ким булмаска тиеш, яки белгечлек буенча эш стажы , әзерлек юнәлеше 3 елдан да ким булмаска тиеш;

алдан баручы төркемнең бөтен категорияләрендәге гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен – өлкән яки кече төркем гражданлык хезмәте вазифаларында гражданлык хезмәте стажы бер елдан да ким булмаска тиеш, яки белгечлек буенча эш стажы , әзерлек юнәлеше ике елдан да ким булмаска тиеш;

өлкән яки кече төркем гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен гражданлык хезмәте стажына, яки белгечлек буенча эш стажы на, әзерлек юнәлешенә квалификацион таләпләр куелмый.

Гражданлык хезмәте стажын билгеләгәндә, аңа федераль дәүләт гражданлык хезмәтенең туры килгән вазифа төркемнәре һәм аларга тиңләгән хәрби һәм хокук саклау хезмәте, ә шулай ук муниципаль хезмәт вазифасының туры килгән төркемнәре кертелә.

4. Гражданлык хезмәткәренең вазифаи регламенты белән куелган, вазифаи бурычларын үтәү өчен кирәкле, профессиональ белемнәргә һәм күнекмәләргә куелган квалификацион таләпләр.

2014 елның “19”август “ 112-тэ
Татарстан республикасының хайваннар
дөньясы объектларын саклау һәм
файдалану Идарәсе боерыгы белән
расланган Кагыйдәнамәгә
2 нче кушымта.

**Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы (кадрлар резервына кертү) кандидатлар бирә торган документлар һәм әсбаплар**

**ИСЕМЛЕГЕ.**

1. Бәйгедә катнашырга теләүче Россия Федерациясе гражданы, Идарәгә киләсе документларны тапшыра:

1) шәхси гариза (гамәлдәге Исемлеккә кушымта);

2) 2005 елның 26 маеннан №667-Р Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыгы белән урнаштырылган, үз кулы белән тутырган һәм имза куйган, фотографиясен куйган анкета;

3) паспорт яки аны алмаштыручы документның күчермәсен (документ шәхси бәйгегә килгәч күрсәтелә);

4) кирәкле һөнәри белем алуны, һөнәрчелекне һәм эш стажын раслый торган документлар:

эш урыны буенча кадрлар хезмәте яки нотариус белән расланган,эш китабының күчермәсе ( искәрмә артыннан эшчәнлек беренче тапкыр алып барылган очракларда),яки гражданның хезмәт эшчәнлеген раслый торган башка документлар;

эш урыны буенча кадрлар хезмәте яки нотариус белән расланган, һөнәри белем алу, һөнәрчелек турында документларның күчермәсе, ә шулай ук теләк буенча өстәмә белем алу нәтиҗәләре буенча һөнәрчелек алуны яки күтәрүне раслый торган документларның күчермәсен, фәнни дәрәҗә, фәнни исем алу турында документларның күчермәсен;

5) хисап чоры өчен керемнәр, милек һәм милки характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар;

6) № 001-ГС/у формасы буенча, гражданинда, гражданлык хезмәтенә керергә яки аны үтәргә кымачаулый торган, авыру булмау турында документ;

7) 2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Федераль канун, башка федераль кануннар, Россия Федерациясе Президенты боерыклары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән каралган, башка документлар.

2. Идарәдә уздырыла торган бәйгедә катнашырга теләүче, анда гражданлык хезмәте вазифасын алмаштыра торган гражданлык хезмәткәре, Идарә башлыгы исеменә гариза бирә.

Бәйгедә катнашырга теләүче, башка дәүләт әгъзасында эшли торган гражданлык хезмәткәре, Идарә башлыгы исеменә гариза һәм үз кулы белән тутырган, имза куйган һәм гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәте вазифасын алмаштыра торган дәүләт әгъзасының кадрлар хезмәте белән расланган, фотографиясен куйган анкета бирә.

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы (кадрлар резервына кертү) кандидатлар бирә торган документлар һәм әсбаплар исемлегенә кушымта

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгына

________________________________________
(инициаллар, фамилия)

________________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме)

________________________________________
Торам____________________________
________________________________________
Тел. ____________________________________
(эш телефоны, өй телефоны, кәрәзле телефоны)

Гариза

Мине, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру (кадрлар резервына кертү) өчен бәйгедә катнашуга кертүегезне сорыйм:

________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(вазифа, структуралы бүлекчә)

2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ "Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында"гы Федераль канун белән, 2005 елның 1 февраленнән № 112 "Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәтенә буш урынны алмаштыру өчен бәйге турында"гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы белән,2003 елның 16 гыйнварыннан № 3-ЗРТ "Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында"гы Татарстан Республикасы Кануны, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру (кадрлар резервына кертү) өчен бәйге уздыру турындагы Кагыйдәнамә, шул ук санда буш вазифага куела торган квалификацион таләпләр белән таныштырылдым.

Бәйге уздыруның вакыты һәм урыны турында E-mail яки күрсәтелгән телефон номерына СМС –хәбәр аша хәбәр алу белән риза.

Гаризага беркетәм: (куелган документларны санап чыгарга).

________________________________________________________________________________

____________ ____________ ____________________
(вакыт) (имза) (имзаның шифрын чишү)

2014 елның “19” август № 112-тэ
Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе боерыгы белән расланган Кагыйдәнамәгә
3 нче кушымта.

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгына
________________________________
(инициаллар, фамилия)

**ГАРИЗА**

« »________________20___ел.

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру (кадрлар резервына кертү) өчен, Сездән бәйге игълан итүегезне сорыйм.

________________________________________________________________
(вазифа исеме)
________________________________________________________________
(бүлек исеме)

Бу вазифаны алмаштыручы кандидатка киләсе таләпләр куела:
________________________________________________________________
(таләпләрне санап китәргә)

Кушымта: хезмәттәге регламентның күчермәсе.

______________________ ______________ ______________________
(алмаштыра торган вазифа) (имза) (фамилия һәм инициаллар)

ЯРАШТЫРЫЛГАН
Идарә башлыгы урынбасары
________________ ________________
(имза, вакыт) (фамилия һәм инициаллар)

2014 елның “19” август “ 112-тэ
Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе боерыгы белән расланган Кагыйдәнамәгә
4 нче кушымта.

____________________________________
(фамилия һәм инициаллар)

Адрес:_____________________________
____________________________________

Хөрмәтле_________________________!

Сезгә, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру (кадрлар резервына кертү) өчен бәйгегә кертелмәвегез турында хәбәр итәм.
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
____________________________________________________________________
(вазифа,бүлек исеме)

Сәбәбе:
(кирәклесен сайларга)

а) Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәтендәге буш урынга куелган таләпләргә туры килмәү;

б) Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәтенә керүгә һәм аны үтүгә, дәүләт гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы канунары белән урнаштырылган чикләүләр;

в) документларны үз вакытында тапшырмау ( аларны сәбәпсез тулы күләмдә бирмәү яки тутыру кагыйдәләрен бозу);

г) тикшерү барышында федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануннары белән тәңгәл килеп, гражданинның Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәтенә керергә комачау итә торган шартлар ачыклану;

Документлар сезгә язмача гариза белән түбәндәге адрес буенча кайтарыла ала. Казан, К.Тинчурин -29, 201 кабинет, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе, телефон: 211 73 81.

Кадрлар хезмәте җитәкчесе ____________________ ______________________
(имза) (фамилия һәм инициаллар)

2014 елның “19”август “ 112-тэ
Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе боерыгы белән расланган Кагыйдәнамәгә
5 нче кушымта.

## БӘЙГЕ КОМИССИЯСЕНЕҢ БЕРКЕТМӘСЕ №________

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсенең бәйге комиссиясе утырышында, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш вазифасын алмаштыруга( кадрлар резервына кертү) бәйге буенча сайлау узды.

________________________________________________________________________________

(вазифаның исеме)

________________________________________________________________________________

(структур бүлекчәнең исеме)

Бәйге комиссиясенең ___ әгъзасыннан утырышта _____ булды.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

1.____________________________________ «уңай»________, «каршы»_______.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

2.____________________________________ «уңай»________, «каршы»_______.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча:

________________________________________________________________________________

(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

бәйге комиссиясе әгъзаларының иң күп тавышын алды, ул сайлауда катнашкан комиссия әгъзалары саныннан_____ процент тәшкил итә.

Бәйге комиссиясе рәисе _______________ ___________________________
(имза) (фамилия һәм инициаллар)

Бәйге комиссиясе рәисенең урынбасары _______________ ___________________________
(имза) (фамилия һәм инициаллар)

Бәйге комиссиясе сәркатибе _______________ ___________________________
(имза) (фамилия һәм инициаллар)

Бәйге комиссиясе әгъзалары _______________ ___________________________
(имза) (фамилия һәм инициаллар)

Бәйгене үткәрү вакыты « »___________20___ел.

2014 елның “19”август “ 112-тэ
Татарстан республикасының хайваннар
дөньясы объектларын саклау һәм
файдалану Идарәсе боерыгы белән
расланган Кагыйдәнамәгә
6 нчы кушымта.

## БӘЙГЕДӘ КАТНАШУЧЫЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

### I. Кандидатның Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең мәдәниятенә туры килү

1. Һөнәри мотивлаштыру

Дәүләт хезмәтендә һөнәри үсешкә омтылу, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәт үсешенә омтылу.

2. Гражданлык позициясе

Эшчәнлектә дәүләткә һәм җәмгыятькә хезмәт итү, канунлыкны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен саклау принципларына ияреп бару.

3. Профессиональ позициянең активлыгы

Куелган максатларны чишүдә инициатива күрсәтү, яхшы нәтиҗәгә ирешер өчен көч куярга әзер булу, стресска бирелмәү.

4. Алгарышка әзерлек

Үзенең белемнәрен, осталыкларын, күнекмәләрен камилләштерүгә омтылыш.

### II. Кандидатның һөнәри компетентлыгы.

5. Белем дәрәҗәсе

Төп һәм өстәмә белемнең дәрәҗәсе һәм сыйфаты.

6. Һөнәри тәҗрибә

Туры килүче һөнәри өлкәдә эшчәнлекнең озынлыгы һәм үзенчәлеге: һөнәри эшчәнлектә конкрет нәтиҗәләргә ирешү.

7. Махсус һөнәри белемнәр, осталыклар, күнекмәләр.

Туры килүче өлкәдә, үз эшеңне эффектив эшләргә булыша отрган һөнәри белемнәр дәрәҗәсе, һөнәри эшчәнлекне регламентлаштыра торган кануннарны белү; заманча һөнәри технологияләрен белү.

8. Гомуми күнекмәләр

Санак белән эшли белү, укый-яза белү, чит телләрне белү.

### III. Кандидатның шәхси-эш сыйфатлары

9. Аналитик сәләтләр

Фикерләүнең системалык һәм зирәклек дәрәҗәсе; яңа, стандарт булмаган чишелешләр таба белү.

10. Аралашу күнекмәләре

Эштә аралашу этикасын куллану; үз карашыңны аргументлар кулланып яклый белү; һөнәри диалог алып бара белү.

11. Җаваплылык

Нәтиҗәләргә казану өчен үз өстеңә алынган бурычларны үтәргә әзерлек.

12. Оештыру сәләтләре

Үзеңнең һәм кул астында эшләүчеләрнең эшчәнлеген планлаштыра белү, эшне, вәкаләтне һәм җаваплылыкны бүлә белү исәбенә нәтиҗәләргә ирешү.